**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТОЛБИЩЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422624 с.Столбище,
ул. Советская, д.103
тел: 4-11-59

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СТОЛБИЩЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕНЕН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422624 Столбище авылы,
Совет урамы, 103 нчы йорт,
тел: 4-11-59

**2024елның 27 июле** **13 номер**

# КАРАР

**Кадастр номеры 16:24:150301:1937 булган, Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Столбище авылы адресы буенча урнашкан җир кишәрлеге өчен “Тулай торак” ның (код 3.2.4.) җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы боерык проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында.**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясенең 2004 елның 29 декабрендәге 190 ФЗ номерлы Шәһәр төзелеше кодексына, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы»муниципаль берәмлеге Уставына таянып, тормыш эшчәнлегенең уңайлы шартларына кеше хокукларын, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында КАРАР ИТӘМ:

1. Кадастр номеры 16:24:150301:1937 булган, Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Столбище авылы адресы буенча урнашкан җир кишәрлеге өчен “Тулай торак” ның (код 3.2.4.) җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы боерык проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1 Үткәрү датасы һәм вакыты - 2024 елның 15 августы 14.00 сәгатьтә.

2.2 Үткәрү урыны-Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы, адресы: 422616, Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Столбище авылы, Совет ур., 103 йорт.

2.3 Кадастр номеры 16:24:150301:1937 булган, Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Столбище авылы адресы буенча урнашкан җир кишәрлеге өчен “Тулай торак”ның(код 3.2.4.) җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне, гавами тыңлауларда катнашуга гаризаларны, чыгыш ясау хокукы белән, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлеге башкарма комитетына тапшырырга, ул түбәндәге адрес буенча урнашкан: 422616, Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Столбище авылы, Совет урамы, 103 йорт.

2.4 Чыгыш  ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризаларны бирү срогы 2024 елның 14 августына кадәр.

3. Әлеге карарны “Кама ягы” («Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Столбище авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

4. . Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан  Республикасы**
**Лаеш  муниципаль  районы  Столбище**
**авыл  җирлеге Советы рәисе**
**вазыйфаларын башкаручы                    А.А. Әбдрәфиев**